**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
13.11.2024

КАРАР
№ 1382

«2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында китапханә эшен үстерү» муниципаль программасын раслау турында

«Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 06.08.2019 ел, № 65-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, республика Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү «Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 16.12.2013 ел, № 997 Карарын гамәлгә ашыру, шулай ук Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының комплекслы социаль-икътисадый үсеше бурычларын хәл итү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2025 – 2027 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында китапханә эшен үстерү» программасын (алга таба - Программа) расларга.
2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Җирлекара үзәк китапханәсе» муниципаль бюджет учреждениесен программаны җаваплы башкаручы итеп билгеләргә.
3. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет төзегәндә, әлеге максатларга Нурлат муниципаль районы бюджетыннан җибәрелә торган акчаларның мөмкинлекләрен исәпкә алып һәм чикләрендә Программа чараларын гамәлгә ашыруга акчалар карарга.
4. «2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында китапханә эшен үстерү «муниципаль программасын раслау турында»Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 05 декабрендәге 1577 номерлы карарын 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин